РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Ленина ул., д. 46, с. Тюлячи, 422080

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

Ленин ур., 46 нчы йорт, Теләче авылы, 422080

тел. (факс): (84360) 2-11-89, E-mail: telache@tatar.ru, http://tulachi.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 29 «04» апрель 2026 г.

Теләче муниципаль районы территориясендә Ватанны саклаучылар, шул исәптән махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) катнашучылар истәлеген мәңгеләштерү буенча комиссия төзү турында

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2026 елның 01 апрелендәге 31-12/4634 номерлы хатын карап, тарихи дөреслекне саклау, гражданнарга патриотик тәрбия бирү, шулай ук исән һәм һәлак булган Ватанны саклаучыларга рәхмәт һәм хөрмәт белдерү максатларында, «Һәлак булган Ватанны саклаучыларның истәлеген мәңгеләштерү турында» 1993 елның 14 гыйнварындагы 4292-1 номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә, Теләче муниципаль районы Башлыгы

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Теләче муниципаль районы территориясендә Ватанны саклаучылар, шул исәптән махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) катнашучылар истәлеген мәңгеләштерү буенча комиссия төзергә һәм аның составын расларга (1 номерлы кушымта).
2. Теләче муниципаль районы территориясендә Ватанны саклаучылар, шул исәптән махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) катнашучылар истәлеген мәңгеләштерү буенча комиссия турында нигезләмәне расларга (2 номерлы кушымта).
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының интернет челтәрендәге рәсми сайтында (https://tulachi.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http:/ / pravo.tatarstan.ru).
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башлыгы урынбасары И.Р. Мараковка йөкләргә.

А.Г. Фатхуллин

*Теләче муниципаль районы*
*Башлыгының 04.04 2026 № 29*
*карарына 1 кушымта*

Теләче муниципаль районы территориясендә Ватанны саклаучылар, шул исәптән махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) катнашучылар истәлеген мәңгеләштерү буенча комиссия составы

| | |
|---|---|
| Фатхуллин А. Г. | Теләче муниципаль районы Башлыгы, **комиссия рәисе**; |
| Мараков И. Р. | Теләче муниципаль район башлыгы урынбасары, **комиссия рәисе урынбасары**; |
| Әүхәдиева Г.Х. | Теләче муниципаль район советының оештыру бүлеге баш белгече, **комиссия сәркатибе**; |

***Комиссия әгъзалары:***

| | |
|---|---|
| Арсланов Р. М. | Теләче муниципаль районы иҗтимагый советы рәисе (килешү буенча); |
| Габдрахманов Ф.Р. | «ФОРПОСТ» МБУ директоры; |
| Галимова Ф. М. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Теләче муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Галимҗанов А. М. | Татарстан Республикасында «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциядә катнашучылары дәүләт фондын филиалының социаль координаторы (килешү буенча); |
| Гыйниятуллин Д.С. | Теләче муниципаль районы Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары; |
| Заһидуллин Р.Ш. | Теләче муниципаль районы ветераннар (пенсионерлар) советы рәисе (килешү буенча); |

| | |
|---|---|
| Закиров Ф.Ф. | Татарстан Республикасы Саба һәм Теләче районнарының хәрби комиссары, комиссия рәисе (килешү буенча); |
| Ибраһимов З. З. | Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы; |
| Иксанов Д. С. | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты мәдәният бүлеге башлыгы; |
| Карпова Н.В. | МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» башлыгы; |
| Мөбинов И. В. | Теләче муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе; |
| Нигмәтҗанов Р.В. | Җитәкче урынбасары - Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының территория үсеше бүлеге башлыгы; |
| Низамов Б. М. | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары; |
| Салимов Б.Р. | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мобилизация эшләре буенча ярдәмчесе; |

Теләче муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча).

Теләче муниципаль районы
Башлыгының 04.04 2026 № 29
карарына 2 номерлы кушымта

**Теләче муниципаль районы территориясендә Ватанны саклаучылар, шул исәптән махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) катнашучылар истәлеген мәңгеләштерү буенча комиссия турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Теләче муниципаль районы территориясендә Ватанны саклаучылар, шул исәптән махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) катнашучылар истәлеген мәңгеләштерү буенча комиссия турында нигезләмә комиссиянең (алга таба – Комиссия) вәкаләтләрен һәм эш тәртибен билгели.

1.2. Комиссия Теләче муниципаль районы территориясендә Ватанны саклаганда һәлак булганнарның истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләләрен объектив карау һәм хәл итү максатыннан төзелгән даими эшләүче коллегиаль киңәшмә органы булып тора.

1.3. Комиссиянең эшчәнлеге ачыклык, уңайлылык, ышанычлылык һәм үз эшчәнлеге турында мәгълүматны үз вакытында тәкъдим итү принципларына нигезләнә.

1.4. Комиссия үз эшчәнлегендә «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законга, «Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү турында» 1993 елның 14 гыйнварындагы 4292-1 номерлы Россия Федерациясе Законына, «совет халкының 1941-1945 еллар Бөек Ватан сугышында җиңүен мәңгеләштерү турында» 1995 елның 19 маендагы 80-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон белән эш итә.

1.5. Комиссия эшчәнлегенең оештыру-техник тәэмин ителеше Теләче муниципаль районы Советы аппараты (алга таба – Совет) тарафыннан башкарыла.

1.6. Ватанны саклаучыларның хәтерен мәңгеләштерүнең төп формалары 1993 елның 14 гыйнварындагы № 4292-I «Ватанны саклаганда һәлак булганнарның хәтерен мәңгеләштерү турында» Россия Федерациясе Законының 2 статьясында билгеләнгән.

## 2. Комиссиянең компетенциясе

2.1. Комиссия, ватандашларның, оешмаларның һәм башка иҗтимагый берләшмәләрнең килгән гаризалары, мөрәҗәгатьләре нигезендә, Теләче

муниципаль районы территориясендә Ватанны саклаганда һәлак булганнарның хәтерен мәңгеләштерү мәсьәләләрен карап, карарлар кабул итә.

2.2. Комиссия Теләче муниципаль районы территориясендә Ватанны саклаганда һәлак булганнарның хәтерен мәңгеләштерү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр инициаторы булып тора ала.

## 3. Комиссиянең хокуклары

3.1. Комиссия үз вәкаләтләре чикләрендә, Комиссиянең компетенциясенә керүче мәсьәләләр буенча гражданнарның мөрәҗәгатьләрен, коллектив мөрәҗәгатьләрен карап чыга.

3.1.2. Үз компетенциясенә кергән мәсьәләне караганда, Комиссия түбәндәге хокукка ия:

3.1.2.1. күтәрелгән мәсьәлә буенча уңай карар кабул итү;

3.1.2.2. гариза иясе үтенечен үтәүдән мотивланган кире кагу чыгару;

3.1.2.3. кирәкле документлар тәкъдим ителгәнгә яки мәсьәләне өстәмә өйрәнүгә кадәр карар кабул итүне кичектерү;

3.1.2.4. мөрәҗәгатьне гариза иясе катнашында карау;

3.1.2.5. Комиссиягә карау өчен тәкъдим ителгән документларда булган мәгълүматны тикшерү өчен эшче төркемнәр булдыру;

3.1.3. комиссия кабул ителгән карарлар турында мәнфәгать табышында булган тарафларны хәбәрдар итә.

## 4. Комиссиянең эшчәнлегенең төп юнәлешләре

4.1. Ватанны саклаганда һәлак булганнарның хәтерен мәңгеләштерүгә юнәлтелгән тәкъдимнәрне һәм проектларны карау.

4.2. Теләче муниципаль районы территориясендә монументаль характердагы һәйкәлләрне, архитектура яки башка корылмаларны күчерү һәм сүтү буенча карарлар кабул итүдә һәм бәхәсләшүдә катнашу.

4.3. Теләче муниципаль районында һәлак булганнарның хәтерен мәңгеләштерүче һәйкәл корылмалары, һәйкәлләр, истәлек такталары, башка истәлек билгеләрен булдыру, урнаштыру һәм сүтү тәкъдимнәрен карау.

4.4. Мемориаль корылмаларны, һәйкәлләрне, истәлек такталарын һәм башка истәлек билгеләрен саклауга караган реставрация һәм ремонт эшләрен үткәрү буенча мәсьәләләрне һәм тәкъдимнәрне кертү һәм фикер алышу.

4.5. Ватанны саклаганда һәлак булганнарның җирләнү урыннарын саклау һәм төзекләндерү, шулай ук хәрби җирләү урыннарын саклау һәм төзекләндерү турында тәкъдимнәрне карау.

4.6. Урамнарга һәм мәйданнарга, оешмаларга, шул исәптән мәгариф оешмаларына, учреждениеләргә Ватанны саклаганда һәлак булганнарның исемнәрен бирү турындагы тәкъдимнәрне карау.

4.7. Ватанны саклаучылар истәлеген мәңгеләштерү буенча башка чаралар турындагы тәкъдимнәрне карау.

4.8. Ватанны саклаучылар истәлеген мәңгеләштерү формаларының кабул ителгән һәм каралган тәкъдимнәре буенча уңай яки тискәре карар кабул итү.

4.9. Комиссиянең вәкаләтенә кергән мәсьәләләр буенча карарлар кабул иткәндә иҗтимагый фикерне исәпкә алу һәм анализлау.

## 5. Ватанны саклаучылар хәтерен мәңгеләштерү буенча карарлар кабул итүнең нигезләре булган критерийлар

5.1. Критерийлар түбәндәгеләр:

- Ватанны саклауда сугыш хәрәкәтләре вакытында, башка сугыш бурычларын үтәгәндә яки хезмәт вазыйфаларын үтәгәндә һәлак булу;
- башка дәүләтләр территориясендә хәрби бурычны үтәгәндә һәлак булу;
- Ватанны саклаганда алынган яралар, контузияләр, җәрәхәтләр яки авырулар нәтиҗәсендә вафат булу, күрсәтелгән нәтиҗәләрнең килеп чыгу вакытына бәйсез, шулай ук сугыш хәрәкәтләре вакытында, башка сугыш бурычларын үтәгәндә яки хезмәт вазыйфаларын үтәгәндә хәбәрсез югалу;
- Ватанны саклаучы тарафыннан эшләнгән эшнең әһәмиятлелеге;
- Ватан алдында казанышларның булуы;
- Ватанны саклаучының Россия Федерациясе алдындагы казанышларын тарихи-архивлык һәм бүләкләү документлары белән раслау;
- Ватанны саклаучылар үзләренең хөрмәтен һәм дәрәҗәсен югалтмыйча һәм Ватанга хыянәт итмичә, барлыкка килгән сугыш ситуациясе нәтиҗәсендә әсирлеккә төшеп һәлак булу, үлем.

## 6. Комиссиянең составы һәм эш тәртибе

6.1. Комиссияне булдыру, аның шәхси составын раслау һәм үзгәртү турындагы карар Теләче муниципаль районы башлыгының карары белән кабул ителә. Комиссиягә рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм Комиссия әгъзалары керә.

6.2. Комиссия рәисе Комиссия утырышларын үткәрә, аның эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә, рәис урынбасары, сәркатип һәм Комиссия әгъзалары арасында бурычларны бүлә, аларның эшчәнлеген координацияли һәм Комиссияга күчерелгән функцияләрне үтәү өчен җаваплылык йөкли.

6.3. Рәис урынбасары рәис булмаган очракта Комиссия эшчәнлеген җитәкли һәм Комиссияга күчерелгән бурычларны үтәү өчен җаваплылык йөкли.

6.4. Комиссия сәркатибе утырышка материаллар әзерләүне, утырыш протоколларын алуны һәм Комиссия эшчәнлеген тәэмин итү буенча башка функцияләрне башкара.

6.5. Комиссия утырышлары кирәк булганча (гаризалар/мөрәҗәгатьләр килгәндә), әмма кимендә елга бер үткәрелә. Утырыш вакытын һәм урынын Комиссия рәисе билгели. Әгъзалар сәркатип тарафыннан алдагы утырыш

вакыты, урыны һәм көн тәртибе турында утырыш үткәреләчәк көннән ике көн алдан соңга калмыйча хәбәр ителә.

6.6. Өстәмә утырыш үткәрелгәндә, әгъзаларга аны үткәрәчәк көннән бер көн алдан хәбәр ителә.

6.7. Комиссия утырышларына оешмалар һәм учреждениеләрнең җаваплы хезмәткәрләре, шулай ук карала торган мәсьәләләр буенча гариза язучы гражданнар чакырыла ала.

6.8. Комиссия карарлары утырышта катнашучыларның гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

6.9. Комиссия утырышлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул утырыш үткәрелгәннән соң 2 эш көне эчендә әзерләнә. Беркетмәдә утырыш вакыты, каралган мәсьәләләрнең кыскача эчтәлеге, алар буенча кабул ителгән карарлар, әгъзаларның конкрет мәсьәләләр буенча аерым фикерләре күрсәтелә. Куела торган мәсьәләләр буенча уңай карарлар кабул ителгәндә, Комиссия тарафыннан Теләче муниципаль районы территориясендә Ватанны саклаганда һәлак булганнар хәтерен мәңгеләштерү чараларын финанслау чыганагы билгеләнә.

6.10. Утырыш беркетмәсенә утырышта катнашкан барлык әгъзалар кул куя һәм ул идарәдә саклана.

## 7. Йомгаклау нигезләмәләре

7.1. Әлеге Нигезләмәдә чагылыш тапмаган мәсьәләләр Россия Федерациясенең хәзерге законнарына туры китерелеп хәл ителә.